**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2016 елның 2 сентябре №41

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Олы Җәке авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 декабрендәге 15-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турында нигезләмә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр туктатылган очракта, 35 статьясындагы 16 өлешенең җиденче абзацында, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьясындагы 6.1 өлешендә, 7.1 өлешендә, 10 өлешенең 5 - 8 пунктларында, 40 статьясындагы 10.1 өлешендә, 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча түләнми «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru - Интернет челтәрендә урнаштырырга.

Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф. А. Фәйзуллина